СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 г. Заинск № 339

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 34.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы Татарстан

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәнең 35.1. статьясындагы 10 өлешенә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 14.11.2014 № 414, 04.03.2015 № 438, 21.05.2015 № 455, 16.10.2015 № 14, 18.12.2015 № 35, 26.08.2016 № 136, 15.12.2016 № 186, 29.03.2017 № 205, 05.07.2017 № 220, 07.09.2017 № 232, 10.09.2018 № 332, 22.04.2019 № 390, 30.09.2019 № 438, 11.03.2020 № 485, 03.06.2020 № 530, 11.11.2020 № 11, 03.03.2021 № 35, 07.10.2021 № 172, 04.03.2022 № 206, 27.01.2023 № 270, 10.08.2023 № 287, 30.11.2023 № 301, 2024 елның 18 апрелендәге 330 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә, беренче тәкъдимне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән,тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Зәй муниципаль районы Башлыгы урынбасары П.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**